КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 59

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2009 ел, 29 март, 242 нче карары белән расланган 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2009 ел, 29 март, 242 нче карары белән расланган 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 29 март, 242 нче
карары белән раслангынды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 гыйгвар, 59 нчы
карары редакциясендә)

«2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасы (алга таба – Программа) |
| Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаның төп Эшләүчесе | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Бюджет акчаларын баш бүлүче | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары |
| Программа белән идарә итү һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаны гамәлгә ашыруны гомуми контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра;<br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Программаны башкаручылар белән үзара хезмәттәшлекне, Программа чараларын гамәлгә ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм тикшереп торуны оештыра |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Торак фондының яшәү өчен яраксызлыгын тотрыклы киметүне тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру;<br>«Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 185-ФЗ номерлы Федераль закон) |

| | |
|---|---|
| Программаның төп максатлары | Билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә) |
| Программаның төп бурычлары | Авария хәлендәге һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә) |
| Программада катнашучылар (Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм берәмлекләре) | Әгерже, Актаныш, Арча, Балтач, Алабуга, Зеленодольск, Кукмара, Минзәлә, Саба, Чистай муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2019-2025 еллар, шул исәптән:<br>2019 ел этабы – 2020 елның 31 декабренә кадәр;<br>2020 ел этабы – 2021 елның 31 декабренә кадәр;<br>2021 ел этабы – 2022 елның 31 декабренә кадәр;<br>2022 ел этабы – 2023 елның 31 декабренә кадәр;<br>2023 ел этабы – 2024 елның 31 декабренә кадәр;<br>2024 ел этабы – 2025 елның 1 сентябренә кадәр.<br>185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау түбәндәге акча хисабына башкарыла:<br>Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды (алга таба – Фонд) – 787,25 млн. сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты – 253,16 млн. сум.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме – 1 040,41 млн. сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Төп чаралар нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары программаның 1 нче кушымтасында китерелгән.<br>Программаның үтәлешенең планлаштырылган күрсәткечләре программага 5 нче кушымтада китерелгән |

## I. Татарстан Республикасында торак фондының бүгенге торышы

Татарстан Республикасында торак фонды мәйданы 101 854,8 мең кв.метр тәшкил итә, шуның 92 проценты хосусый милектә (94 504,1 мең кв. метр), 6 проценты – муниципаль милектә (5 539,3 мең кв. метр), 2 проценты – дәүләт милкендә (1 811,4 мең кв. метр).

Республикада гомуми мәйданы 76 084,7 мең кв.метр булган 47 185 йорт исәпләнә, шулардан 17 257 күпфатирлы йорт (алга таба – КФЙ) гомуми мәйданы 70 967,5 мең кв. метр булган (блоклы төзелешне исәпкә алмыйча).

2019 елның IV кварталына 146 КФЙ физик тузу сәбәпле авария хәлендә һәм яшәүгә яраксыз дип табылды, алар гомуми мәйданы 42 907,81 кв. метр булган 1 417 бинадан тора, аларда 3 619 кеше яши, шул исәптән:

шәхси милектә – 24 710,59 кв. метрлык 878 бина;

муниципаль милектә – 18 197,22 кв. метрлык 539 бина.

2017 елның 1 гыйнварына кадәр 85 КФЙ авария хәлендә дип танылды, алар гомуми күчерелә торган 21 027,73 кв. метр булган 654 бинадан тора, аларда 1 754 кеше яши, шул исәптән:

шәхси милектә – 11 907,52 кв. метрлык 386 бина;

муниципаль милектә – 9 120,21 кв. метрлык 268 бина.

Муниципаль берәмлекләр тарафыннан авария хәлендәге торак фондының саны турында мәгълүмат «ТКХ реформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелә. Күрсәтелгән белешмәләр муниципалитет җитәкчесенең КФЙ аварияле һәм яшәүгә яраксыз дип тану турындагы карарларының скан-күчермәләре, шулай ук фотоматериаллар белән раслана. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан әлеге мәгълүматларны урынга барып тикшерү үткәрелә.

## II. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Татарстан Республикасында Дәүләт торак сәясәте мәсьәләләренең берсе – гражданнар өчен торак алу мөмкинлеген, анда яшәү өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тәэмин итә торган торак өлкәсе тотрыклы эшләвенә һәм үсешенә күчү проблемасын комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән, авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукын тормышка ашыруны тәэмин итү.

Авария хәлендәге торак фонды программасында КФЙ торак бүлмәләрнең җыелмасы аңлана, алар 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә эксплуатация процессында физик тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип табылган.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе хәзерге вакытта билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торак урыннарын мөстәкыйль сатып ала алмый.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү проблемасын хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларында аларны күчерү өчен җитәрлек акча булмау комачаулый.

Проблема Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына тиешле финанс ярдәме күрсәткәндә хәл ителергә мөмкин.

## III. Программаны тормышка ашыруның төп максатлары, бурычлары һәм сроклары

Программаның төп максатлары булып, җирле үзидарә органы, билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган, җирле үзидарә органы, фонд чаралары хиса-

бына 185-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне тәэмин иткән очракта, авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тора.

Программаны тормышка ашыру кысаларында финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла торган гражданнарны күчерү өчен 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган һәм эксплуатация процессында физик тузу сәбәпле җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле КФЙ исемлеге аңа 2 нче кушымтада китерелгән.

Программаның төп бурычы – авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак фондыннан гражданнарны күчерү.

Программа 2019 елдан 2025 елның 1 сентябренә кадәр гамәлгә ашырылачак.

Программаның гомуми бәясе – 1 040,41 млн. сум.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары 1 нче кушымтада китерелгән.

## IV. Программада катнашучы муниципаль берәмлекләр исемлеге

Программада катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге түбәндәге шартларны исәпкә алып формалаштырылды:

а) муниципаль берәмлек тарафыннан 185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) муниципаль берәмлек территориясендә 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә эксплуатация процессында физик тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип табылган КФЙ бар.

Муниципаль берәмлекләр тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге reformagkh.ru адресы буенча «ТКХ реформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматлар нигезендә гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программалар раслана.

Программаны гамәлгә ашыруда Әгерҗе муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге катнаша.

Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм әлеге муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану елы алдыннан әлеге муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка КФЙ, шулай ук КФЙ җимерелү куркынычы булганда яисә гражданнарны законлы көченә кергән суд карары нигезендә күчергәндә авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану елларына кадәр булган күпфатирлы йортлардан гражданнар беренче чиратта күчерелергә тиеш. Төрле елларда авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган берничә КФЙ планлаштыру структурасының бер элементы (квартал, микрорайон) яки планлаштыру структурасының чиктәш эле-

ментлары чикләрендә урнашкан булса, гражданнарны әлеге йортлардан күчерү авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча региональ адреслы программаның бер этабы кысаларында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Күчерү этапларына кергән КФЙ санын билгеләгәндә, югарыда күрсәтелгән критерийлар һәм күчерү этапларын финанслау лимитлары исәпкә алынган.

## V. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына формалаша. Программаны финанслауның барлык чыганаклары хисабына тормышка ашыруга гомуми чыгымнар 1 040,41 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән акча:

Фонд – 787,25 млн. сум (өлеше 75,7 процент тәшкил итә);

Татарстан Республикасы – 253,16 млн. сум (өлеш 24,3 процент тәшкил итә).

Программаны финанслау чаралары күләме, Программага кертелгән, авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган КФЙ исемлеге нигезендә, гражданнарга бирелә торган торак урыннарының гомуми мәйданының планлаштырыла торган бәясе күләме һәм гражданнар (юридик затлар) милкендәге алына торган торак биналарның гомуми мәйданының бер квадрат метрына планлаштырыла торган сатып алу бәясе күләме белән, программага кертелгән авария хәлендәге КФЙ, шулай ук 3 нче кушымта нигезендә гражданнарны күчерү ысуллары белән билгеләнә.

2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен финанс ярдәме чараларын бүлү программага 4 нче кушымтада китерелгән.

Алына торган торак урыны өчен түләү күләме, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлешендә күчерелгән факторларны исәпкә алып, авария хәлендәге КФЙ урнашкан муниципаль берәмлек тарафыннан билгеләнә. Торак урыны өчен алына торган түләү күләме турында бәхәс туганда торак бинаның базар бәясе «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында»1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда каралган кагыйдәләр буенча билгеләнә.

Программаны тормышка ашырганда сатып алу бәясе муниципаль берәмлек һәм авария хәлендәге торак урыны милекчесе арасындагы килешү нигезендә яки милекченең Программа шартлары белән килешмәгән очракта, суд карары буенча үзгәртелергә мөмкин.

Казан шәһәрендә урнашкан авария хәлендәге торак фондының торак урыннары милекчеләренә башка уңайлыклары булган торак урыннары бирү турындагы суд практикасын исәпкә алып, шулай ук Казан шәһәрендә милекчеләрдән авария хәлендәге торак сатып алуның югары бәясен исәпкә алып, бюджет акчаларын экономияләү максатыннан, Казан шәһәре буенча бюджет акчаларын экономияләү максатыннан, авария хәлендәге торак милекчеләренә аларның ризалыгы белән башка төзекләндерелгән торак урыннарын тәкъдим итү планлаштырыла.

Авария хәлендәге торак фондының торак урыннарын яллаучыларга Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясы нигезендә барлык муниципаль берәмлекләрдә торак урыннары бирелә.

Программа нигезендә бирелә торган торак урыннарның бер квадрат метр гомуми мәйданының планлаштырылган бәясе күләме тәшкил итә:

2019 ел этабы буенча – 41,0 мең сум;

2020 ел этабы буенча – 42,0 мең сум;

2021 ел этабы буенча – 43,0 мең сум;

2022 ел этабы буенча – 44,0 мең сум;

2023 ел этабы буенча – 45,0 мең сум;

2024 ел этабы буенча – 46,0 мең сум.

Күрсәтелгән бәяләр алдан кабул ителде һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен биналар сатып алуга электрон аукцион нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин.

Сатып алына торган торак биналарга карата таләпләр Программаның 6 нчы кушымтасында китерелгән.

Җирле бюджет акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына алынган акчалар бары тик тотыла:

КФЙ (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган КФЙ, гражданнарның һәм (яки) юридик затларның акчаларын җәлеп итеп төзелә торган яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән йортларда (алга таба – блокланган төзелеш йортлары) һәм (яки) мондый йортларны төзүгә сатып алу;

авария хәлендәге торак фондына керүче торак урыннары булган затларга 185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә алына торган торак урыны өчен түләү;

185-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә әлеге биналар урнашкан йортларны төзүче булмаган затларда торак урыннары алу, авария хәлендәге торак фондыннан күчерелүче гражданнарга бирү өчен.

Программаны өлешләп финанслау күләме субъект бюджеты акчалары исәбеннән этаплар буенча тәшкил итә:

2019 ел этабы – 50,2 процент,

2020 ел этабы – 50,6 процент,

2021 ел этабы – 34,1 процент,

2022 ел этабы – 11,6 процент,

2023 ел этабы – 9,2 процент,

2024 ел этабы – 14,5 процент.

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүнең планлаштырылган күрсәткечләре Программаның 5 нче кушымтасында китерелгән.

## VI. Программа чараларын тормышка ашыру механизмы, программа белән идарә итүне оештыру һәм аны тормышка ашыруны контрольдә тоту

Дәүләт заказчысы Программа чараларын финанслауны тәэмин итү өчен Фондка гаризалар бирә, программаны башкаручылар белән планлаштыруны, үзара бәйләнешне, Программа чараларын гамәлгә ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм тикшереп торуны оештыра.

Программаны башкаручы Программа чараларын тормышка ашыру, аларның ахыргы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан максатчан файдалану өчен җавап тота һәм тәэмин итә:

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү муниципаль программасын эшләү һәм раслау;

185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәү;

муниципаль берәмлек территориясендә инвентаризация үткәрү һәм авария хәлендәге торак фондына мониторинг үткәрү;

КФЙ төзелеше очрагында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен билгеләнгән йортлар төзелешенә проект документациясен эшләү;

сатуларны үткәрү һәм КФЙ (блокланган төзелеш йортлары) төзүгә, торак биналар, торак биналарны сатып алу килешүләрен төзүгә муниципаль контрактлар төзү;

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән акчаларны тоту турында хисап алып бару һәм аны дәүләт заказчысына Программа тәкъдим итү;

гражданнарны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган торак фондыннан күчерүгә бәйле рәвештә, социаль наем шартнамәсе буенча яисә торак урынын милеккә тапшыру турындагы килешү буенча торак урыннарын бирү;

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү.

Программаны гомуми җитәкчелекне һәм тормышка ашыруны контрольдә тотуны Программаның дәүләт заказчысы гамәлгә ашыра, ул билгеләнгән вакытта Фондка программаны гамәлгә ашыру барышы һәм Фондның финанс чараларын тоту турында хисап бирә.

2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына 1 нче кушымта

2019-2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасының төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Программаның үтәлеше күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Программаның үтәлеше нәтиҗәсендә ирешелгән |
|---|---|---|
| 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын үтәү нәтиҗәсендә күчерелгән кешеләр саны (алга таба – Программа) | кеше | 1 754 |
| Программаны тормышка ашыру кысаларында күчерелгән кешеләр, авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән, аңа кертелгән кешеләрнең гомуми саныннан | процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендәге дип танылган күпфатирлы йортлар саны | данә | 85 |
| Программаны үтәү кысаларында күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| Бушатылган биналарның гомуми саны (найм, сатып алу һәм кимендә берәмлекләрдә һәм квадрат метрларда) Программа кысаларында торак һәм торак булмаган биналар буенча аерым | данә | 654 помещения общей площадью 21 027,73 кв.метра |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендәге барлык күпфатирлы йортларга карата, авария хәлендә дип танылган һәм аларны эксплуатацияләү барышында физик тузу сәбәпле, 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| Программаны үтәү өчен Татарстан Республикасына карата дәүләт корпорациясе – торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд чаралары лимитыннан тотылган акчалар өлеше | процент | 100 |